**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нчейортЛаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2020елның «06» августы 1524номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының” Акыллы балалар” Усад балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен төзү турында.**

Россия Федерациясе гражданлык кодексы, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы (гамәлдәге редакциядә) №7-Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге (гамәлдәге редакциядә - 2019 елның 2 августы) 131номерлы - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, үзгәртү һәм бетерү тәртибен раслау турында, шулай ук район уставларын һәм аларга карарлар кертү турында» 2010 елның 13 декабрендәге 2031 номерлы карары нигезендә, карар бирәм**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Акыллы балалар” Усад балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен түбәндәге адрес буенча төзергә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы, Уютная ур., 3/у 5.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Акыллы балалар” Усад балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Уставын расларга.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Акыллы балалар” Усад балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең штат расписаниесен расларга.

4. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Л.И. Хөсәеновага Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Акыллы балалар” Усад балалар бакчасы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә мөдир билгеләп куярга.

5. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Акыллы балалар” Усад балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдирен Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче номерлы МРИ да юридик затларны теркәгәндә һәм Бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр керткәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга вәкаләтле итәргә.

6. Лаеш муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә әлеге учреждениене финанслауны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарны интернет - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:\\pravo.tatarstan.ru веб-адрес һәм интернет-телекоммуникатив челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http:\\laishevo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Лаеш районы башкарма комитеты» муниципаль учреждениесе җитәкчесенең беренче урынбасары А.Г. Карсаловка йөкләргә.

Җитәкче И.Ф.Зарипов